Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләченең беренче номерлы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе

Раслыйм
Теләченең беренче балалар бакчасы мөдире
______________ / А.Н.Давлетшина/
Балалар бакчасының педагоглар киңәшмәсендә каралды. Беркетмә № 1.
Приказ № 94 28.08.2023 ел.

2023-2024 нче уку елына
татар балаларын ана теленә өйрәтү буенча
эш программасы

Татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче:
Сабирзянова Л.М.

2023-2024 уку елы

ЭЧТӘЛЕК.


| | |
|---|---|
| **1.Программаның максатчанлык бүлеге** | |
| 1.1. Аңлатма язуы | 2 |
| 1.1.1. Эш программасының максаты һәм бурычлары | 3 |
| 1.1.2. Эш программасының принциплары | 3 |
| 1.2. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | 4 |
| 1.3. Диагностик матераллар | 6 |
| **2. Программаның эчтәлек бүлеге** | 9 |
| 2.1. Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге. | 9 |
| 2.2. Балаларны Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп татар теленә өйрәтү. | 10 |
| 2.3. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру | 11 |
| 2.4. Ата- аналар белән эш. | 12 |
| **3. Программаның оештыру бүлеге.** | |
| 3.1. Баланың үсеше өчен психолого-педагогик шартлар | 14 |
| 3.2. Предметлы-үстерелешле әйләнә тирәлек | 21 |
| 3.4. Материаль – техник тәэмин ителү | 21 |
| 3.6. Белем бирү эшчәнлеген оештыру. | 22 |
| 3.7. Көн тәртибе | 35 |
| 3.9. Норматив-методик документлар | 38 |
| 3.10.Кулланылган әдәбият исемлеге | 39 |
| 3.11.Программага өстәмәләр | 40 |


**Аңлатма язуы**

Балалар бакчасында йөрүче балаларга татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартына (ФДББС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

Федераль җирлегендә:

- 29.12.2012 елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- СанПиН 2.4.1.3049-13 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр” раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2013 ел 15 май 26 нчы номерлы боерыгы;

Төбәк җирлегендә:

- Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы, № 1560-XII,

8/07/1992(ТР Законы ред. № 44-ЗРТ, 28.07.2004; № 54-ЗРТ, 3.12.2009; № 16-ЗРТ, 03.03.2012; № 53-ЗРТ, 12.06.2014);
Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:
- МБМБУ Уставы;
- МБМБУнең төп белем бирү программасына таянып эшләнде.

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартларын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

**1.1.1.Программаның максаты:**

Программаның максаты: Информацион-коммуникатив технологияләр, уен-ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, татар теленә өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар: 1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.
4. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**1.1.2. Программа принциплары.**

Программа мәдәни ярашканлык принцибына корылган. Әлеге принципны гамәлгә ашыру белем бирүдә милли кыйммәтләрне һәм традицияләрне исәпкә алуны тәэмин итә, рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбия бирүдәге җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Белем бирү баланы кешелек мәдәниятенең төп компонентларына (белем, әхлак, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак карала. Программа материалын сайлауның төп критерие — аның тәрбияви кыйммәте, кулланылган мәдәният әсәрләренең (илебез, шулай ук чит илләр классикасы һәм халык иҗаты) югары сәнгатьлелек дәрәҗәсе, мәктәпкәчә балачакның һәрбер этабында баланың һәрьяклы сәләтләрен үстерү мөмкинлеге.

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;
• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына ни- гезләнә;
• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;
• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әй- дәп баручы төре булып уен исәпләнә;
• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрлеләндерүгә юл куя;
• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

**1.2. Уку елы ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләре**

Уртанчылар төркеме балаларының уку елы ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләре

| Танып белү | Сөйләм үстерү |
|---|---|
| -таныш һөнәрләр атамасын әйтә ала;<br>-ел фасыллары,аларның билгеләре турында үзләштерә;<br>-туган шәһәребез, Татарстан Республикасы, Рәсәй турында белем үзләштерә;<br>-киемнең үткәне һәм бүгенгесен аңлый;<br>Яңа ел,календарь бәйрәмнәре белән кызыксына | -сүзлек өстендә эшли ала;<br>-сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыра;<br>-сөйләмендәге аваз культурасы уңай;<br>-бәйләнешле сөйләм теле әйбәт;<br>-бирелгән әсәрне аңлый;<br>-тәрбияче артыннан персонажның кайбер фразаларын кабатлый ала;<br>-шигырьне яттан сөйләргә омтыла;<br>-матур әдәбият белән кызыксына;<br>-конкрет-образлы фикерли |

Зурлар төркеме балаларының уку елы ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләре

| Танып белү | Сөйләм үстерү |
|---|---|
| - транспорт төрләрен кешетормышынҗиңеләйтә,уңайлыклар тудыра торган әйберләрне белә;<br>- предметның төсе,күләме, формасын аера,<br>зурлыгы, авырлыгы,<br>нинди материалдан | - сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана;<br>- үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи;<br>- әкиятләрнең ахырын тәмамлый, зур |

| | |
|---|---|
| эшләнгән булуы турында сөйли ала,аларны төркемли;<br>- төрле һөнәрләр(төзүчеләр, авыл эшчәннәре һ.б.) турында белә;<br>- туган шәһәрен(авылын), туган илен,аның башкаласын, юл йөрү кагыйдәләрен белә;<br>- үз туганнары, үзе турында сөйли ,<br>өй адресын әйтә;<br>- табигатькүренешләрен күзәтеп, алар арасындагы бәйләнешләртурында нәтиҗә чыгара ала, кайбер закончалыкларны белә. | булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә интонацияләрдән дөрес файдалана;<br>- сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана;<br>- мәгънәдәш сүзләр һәм капма-каршы сүзләр куллана;<br>- аралашуда актив була, теләп катнаша.<br>- әсәрнең жанрын билгели ала(әкият, хикәя, шигырь);<br>- зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерә,рольләргә бүлеп шигырьләрне сөйли;<br>- яраткан язучыларны атый белә;<br>- укыту методик комплектында күрсәтелгән<br>2 – 3 шигырьне сөйли, табышмак,мәкальләрне искә төшереп әйтә;<br>- әдәби персонажның кылган гамәлләре турындагы фикерләрен башкаларга сөйли;<br>- үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белә |

Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының уку елы ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләре

| Танып белү | Сөйләм үстерү |
|---|---|
| - сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый;<br>- экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә;<br>- табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматлы;<br>- предметларны үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары буенча аерып ала һәмтөркемли белә;<br>- үзе, эти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын,телефон номерын әйтә ала),<br>өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында белә | - күмәк сөйләмдә катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле һәм аңлаешлы итеп сөйли);<br>- сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана;<br>- сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белү күнекмәләре бар;<br>- предметлар, картиналар,рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, иҗади хикәяләр төзи белә;<br>- тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә;<br>- әсәрнең жанрын билгели ала (әкият хикәя, шигырь); |

| | |
|---|---|
| | - китап геройларының хәленә керә белә,<br>кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз<br>мөнәсәбәтен  белдерә;<br>- шигырьләрне, сәхнәләштергән<br>әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли,<br>эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә<br>белә;<br>- иллюстрацияләр,  рәсемнәргә карап,<br>өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен<br>таный;<br>- китаплардан яңа белемнәр алу<br>мөмкинлеген аңлый. |

**1.3. Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече**

Диагностика күрсәткечләре барлык белем бирү өлкәләре (социаль-аралашу, танып-белү, сөйләм үсеше, нәфис-нәффәсати, физик культура) буенча баланың үсеш дәрәҗәсен, үзләштерүдә булган кыенлыкларны, шулай ук аларның сәләтләрен дә ачыкларга ярдәм итә. Диагностика нәтиҗәләре <u>бары </u>тәрбияче өчен генә. Әлеге нәтиҗәләргә таянып, тәрбияче алга таба кайсы бала белән, индивидуаль рәвештә нинди юнәлеш буенча  эш алып  бару өчен кирәк.

*(зурлар төркеме)*

Танып белү

Югары дәрәҗә (3 балл). Бала транспорт төрләрен, кешетормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрнетаный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авылэшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөресәйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанныңбашкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли,адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алараpасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәпсөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре,авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең,Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзарабәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

Түбән дәрәҗә (1 балл). Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәманың үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авылэшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре(авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтәбелми. Үз туганнары, үзе турында

тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата,үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.
Сөйләм үстерү
Югары дәрәҗә (3 балл). Сөйләмдә төрле кушма җөмләләркуллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенчамөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләпкатнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.
Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне,мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана.
Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Сөйләмдә төрле кушма җөмләләркулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйльтүгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләртөзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балаларбелән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя)аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендәүзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә,рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкинкатнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыкларкичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә,хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларгатулы итеп сөйләми.
Түбән дәрәҗә (1 балл). Бала сөйләмдә гадиҗөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли,эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбиячеярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдәнфайдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлысүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрнеәйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша,үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.
Әсәрнең жанрын(әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый.Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәбиперсонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенеңяраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

**Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече**
*(мәктәпкә әзерлек төркеме)*

Танып белү
Югары дәрәҗә (3 балл). Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә. Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә ала), өлкәннәр хезмәте,аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматы бар.
Уртача дәрәҗә (2 балл). Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата.Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйләгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә, үзлектән төзәтә белә. Үзе (фамилиясе, исеме,әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы тулы түгел.
Түбән дәрәҗә (1 балл). Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, әмма аларны төркемләми. Үзе (фамилиясе,исеме, әтисенең исеме,адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.
Сөйләм үстерү
Югары дәрәҗә (3 балл). Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар,фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана ала. Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.
Әсәрнең жанрын билгели ала(әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштерелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли,эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр,рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный. Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.
Уртача дәрәҗә (2 балл). Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларныаз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар,күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар,рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә, хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь)хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелек җитми. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә, хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр,

рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, хаталар җибәрә, күп очракта үзлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.
Түбән дәрәҗә (1 балл). Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый; вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә.
Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төземи.
Бала әсәрнең жанрын(әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә,сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

## 2. Программаның эчтәлек бүлеге

2.1. Программа нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөстәкыйль рәвештә мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасының вариатив өлешен эшли, раслый һәм тормышка ашыра; шуның белән балаларның физик, социаль һәм акыл үсеше хокукларын (Бала хокуклары турындагы Конвенция, 1989), барлык балалар өчен мәктәпкәчә баскычтан башлангыч мәктәпнең беренче сыйныфына укырга күчкәндә тигез мөмкинлекләрен тәэмин итә.
Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә әйдәп баручы белгечләр хезмәтләрендә (Л.С.Высотский, П.Я.Гальперин, В.В.Давыдов, А.В.Запорожец, А.Н.Леонтьев,С.Л.Рубенштейн һ.б.) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген көйләп торучы башка норматив-хокукый актлар положениеләренә нигезләнә. Программа мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсеше проблемасына мәдәни-тарихи якын килүгә туры китереп эшләнде,анда фәнни нигезләнү һәм гамәли кулланыш принциплары берләштерелде. Программаны гамәлгә ашыру белем бирү процессын төзүнең комплекслы тематик принцибына, мәктәпкәчә белем бирүнең бөтенлек һәм интеграция принципларына нигезләнде, балаларның яшьләренә туры килгән эш формаларын һәм эшчәнлек төрләрен исәпкә алып төзелде.
Программа балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү,рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура,туган якны, туган телне өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота. «Милли культураны, үз халкыңның рухи байлыгын  өйрәнү, аны шушы җирдә яшәгән башка халыклар культурасы белән баету, баланың культурага булган билгеләмәсе киләчәктә аңа бөтендөнья культурасын аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз халкының культурасына булган шундый киң караш, аны зуррак масштабтагы культура процесслары контекстларында кабул итүгенә иҗади шәхес формалашуга һәм үсешенә нигез булып торачак, ул үз чиратында милли культураны

пассив күзәтергә генә түгел, ә аңа шәхсән үз өлешен кертергә, культура барлыкка килү процессында катнашырга мөмкинлек бирәчәк» (Ф. Ф. Харисов).

Татар телен өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы ” нигезендә төзелде.
«Танып белү-сөйләм үсеше» юнәлеше эчтәлегендә татар теленә тирән кызыксыну, туган телдә аралашуга теләк уяту бурычы куелды. Балалар матур дәбияты, уку-укыту методик комплекты, аудио-, видеоязмалар, мәгълүмати-аралашу технологияләре авазларның дөрес әйтелешенә, билгеле күләмдә сүзлек байлыгына, сөйләмнең сәнгатьлелегенә нигез салырга ярдәм итәчәк.Тарих, культура, архитектура, туган якның табигате белән танышу өлкәсендә махсус танып белү бурычлары куелды.

**2.2. Балаларны Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп татар теленә өйрәтү.**

Балаларны татар теленә өйрәтү кечкенәләр төркеменнән башлана. Ул беренче кечкенәләр төркемендә ун,  икенче кечкенәләр төркемендә – унбиш, уртанчылар төркемендә – унбиш  минутлык, уен формасында, атнага өч тапкыр режим вакытында үткәрелә.
Балаларны татар теленә зурлар төркеменнән  эшчәнлектә  өйрәтә  башлыйбыз. Бу яшьтәге балаларга тел өйрәтү өчен атнасына 25 әр минут икешәр эшчәнлек(берсе режим вакытларында), мәктәпкә әзерлек төркемендә 30 ар минутлык өчәр эшчәнлек бирелә. Бу вакытны эш төрләре буенча тәрбияче планлаштырылган тәрбия һәм белем бирү процессына яраклаштырып бүлә.
Тәрбиячегә татар телен өйрәнүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның телне ясалма тудырылган тел мохитендә үзләштерүләрен онытмаска кирәк. Тел мохите үстерешле характерда булырга тиеш. «Үстерешле тел мохите» төшенчәсе баланың үз тел тирәлеген (тел мохите), шулай ук үстерешле предметлы мохитне (тирәлекне) дә үз эченә ала. Татар телен өйрәтү шөгыльләре өчен махсус бүлмәләр булдыру зарур.
Мәктәпкәчә учреждениедә татар теленә өйрәтүдә тәрбияченең сөйләме балаларны өйрәтерлек булсын өчен, түбәндәге шартларны исәпкә алырга кирәк:
– татар телен өйрәтүче тәрбияченең сөйләме балаларга аңлаешлы булырга тиеш; озын һәм төзелеше буенча катлаулы җөмләләрне кулланудан сакланырга кирәк;
– тәрбияченең нәрсә әйткәнен бала аңламаса, кабатлап әйтергә, икенче төрле итеп әйтергә һ. б. ысуллар куллану тәкъдим ителә;
– белем бирү процессы баланың сөйләм үсеше бурычларын эзлекле рәвештә катлауландыру, эшлекле якын килү нигезендә төзелә.
Белем бирү процессын билгеле бер тәртиптә төзегәндә, белем бирү бурычлары бер-берсен тулыландыра ала. Шундый мөмкинлекләрне белем бирү процессын планлаштырганда истә тотарга кирәк. Белем бирү процессын планлаштыру балаларның үзләренәгенә хас булган төрле эш төрләре комплексын «уртак тема»тирәли берләштерүен күздә тота. Теманы сайлаганда, инициатива педагоглар, балалар һәм аларның әти-әниләренә бирелергә мөмкин. «Тематик атналар», «Вакыйгалар», «Проектлар», «Табигатьтә ел фасыллары күренешләре», «Бәйрәмнәр», «Йолалар» һ.б.

Эчтәлекне планлаштырганда, өлкәннәр белән балаларны үзара мөгамәләләренең төрле формаларын файдалануны күздә тоту мөмкин: турыдан-туры, турыдан-туры булмаган белем бирү, тигез хокуклы хезмәттәшлек.
Өлкәннәр белән балаларның һәм балаларның үзара партнёрлык эшчәнлеге үзләштерүнең төрле этапларында ешрак файдаланыла, бу – эчтәлекнең үзенчәлегенә һәм балаларның тәҗрибәсенә бәйле.Баланың аңы өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән уртак эшчәнлектә генә түгел, ә мөстәкыйль эшчәнлектә дә үсә. Шуңа күрә тәрбиячегә төркемдә баланың үзлегеннән үсеш процессына, мөстәкыйль иҗади башлангычларына этәргеч көч булып торган предметлы-үстерелешле мохит оештыру мөһим. Төрле яшьтәге балалар белән тәрбия һәм белем бирү процессын планлаштыруның үзенчәлекләре бар. Кечкенәләр, уртанчылар,зурлар төркемнәрендә белем бирү процессы күбесенчә ирекле формаларда оештырылса, мәктәпкә әзерлек төркемендә махсус оештырылган өйрәтү шөгыльләренә мөһим урын бирелә. Шөгыльләрдә уку-укыту методик комплектын куллану, укыту һәм уен бурычларын кертү белем бирү эшчәнлеге элементларының үсешенә (бурычны кабул итәргә өйрәнү, инструкция буенча эш итү, үз-үзеңне тикшереп торуга) ярдәм итә. Ләкин бу очракта оештырылган белем бирүнең ролен арттырмаска кирәк. Яшь үзенчәлекләре буенча, балаларга тормышчан вакыйгаларны күзәтү, билгеле әйберләр белән эш итү, уен һәм ярыш характерындагы эшчәнлекаеруча якын.
Тәрбия һәм белем бирү процессын проектлаштырганда, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагогларының(тәрбиячеләр, логопедлар, физик культура инструкторлары,музыка җитәкчеләре)эшчәнлеген планлаштыру аша берләштерү мөһим. Мәктәпкәчә мәгарифнең төбәк программасын тормышка ашыруда педагоглар эшчәнлеге эчтәлеген үзара килешү буенча системалы эш алып бару зарур. Балаларның билгеле бер эчтәлекне үзләштерүләре йомгаклау вакыйгасы – ял вакыты, бәйрәм,спектакль, күргәзмәләр оештыру белән тәмамланырга мөмкин.Анда балалар алган белемнәрен йомгаклыйлар, үзләренең уңышларын күрсәтәләр. Әгәр дә сценарийга алынган белемнәрне куллануны таләп итүче ярыш моментлары, викторина элементлары, гамәли биремнәр кертелсә, бу чаралар балалар бакчасындагы педагогик процесс барышын күзәтүнең үзенчәлекле ысулы булып тора ала.

**2.3. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру**

Программаны үзләштерү, тормышка ашыру буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеге көндәлек режимда ике төп модельдә оештырыла: өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.Белем бирү мәсьәләләренең чишелеше беренче модель кысаларында – өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә – турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге төрендә дә, шулай ук режим вакытларында бара торган белем бирү эшчәнлеге төрендә дә тормышка ашырыла. Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге вакыт белән билгеләнгән шөгыльләрдә түгел, ә бәлки педагог үз теләге белән бала эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, хәрәкәт, танып белү тикшеренү, аралашу, музыкаль, сәнгать, хезмәт эшчәнлеге,шулай ук матур әдәбият уку) оештыру аша яки аларны төрле формалар (проблемалы уен ситуациясе, матур әдәбият

уку,күзәтү, хәрәкәтле уен, уен күнегүләре, эксперимент-тикшеренү эшләре, проект эшчәнлеге һ. б.) кулланып берләштергәндә тормышка ашырыла.

**2.4. Ата-аналар белән эш.**

Төп максатлар һәм бурычлар.

Гаилә белән конструктив багланышлар үстерү бала шәхесенең тулы үсешен тәэмин итүнең иң мөһим шарты булып тора. Төп максат — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы үзара мөнәсәбәтләр формалаштыру һәм ата-аналарның компетентлыгын (бала тәрбияләү белән бәйле төрле типтагы социаль-педагогик ситуацияләрне хәл итә алу сәләтен) үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру; ата-аналарның ихтирамлы һәм аңлаулы мөнәсәбәткә, балалар бакчасы тормышында катнашуга хокукын тәэмин итү.

Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә үзара мөнәсәбәтләрдә субординациядән, монологизмнан арыну, бер-берләрен гаепләү гадәтеннән баш тарту, бер-берләрен үз проблемаларын хәл итү чарасы итеп түгел, ә тигез хокуклы партнерлар, хезмәттәшләр итеп күрә белү зарур.

Балалар бакчасының гаилә белән багланышларының төп бурычлары:

• педагогларның һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү, өйрәтү-укыту, үсешләренә ирешү, балалар бакчасында һәм гаиләдә төрле эшчәнлекне оешты- ру шартларына кагылышлы төрле мәсьәләләргә карата мөнәсәбәтләрен өйрәтү;

• педагогларны һәм ата-аналарны балалар бакчасында һәм гаиләдә тәр- бияләүнең иң отышлы тәҗрибәсе, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә һәм җәмгыятьтә тәрбияләүдә туган кыенлыклар белән таныштыру;

• балаларны тәрбияләүнең һәм өйрәтү-укытуның актуаль мәсьәләләре, балалар бакчасының һәм гаиләнең әлеге мәсьәләләрне хәл итү мөмкин- лекләре турында бер-берләренә җиткереп тору.

• балалар бакчасында педагогларның һәм ата-аналарның балалар белән үзара конструктив тәэсир итешүе үсешенә булышлык итүче, эчтәлеге һәм формасы буенча төрле булган хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру;

• тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен районда (шәһәрдә, өлкәдә, республи- када) оештырыла торган, педагоглар белән бергә уздырылучы чараларда катнашуга җәлеп итү;

• баланың төрле омтылышларына һәм ихтыяҗларына карата игътибар- лы мөнәсәбәт күрсәткән ата-аналарны хуплау, әлеге ихтыяҗларны гаиләдә канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру. Гаилә белән ике арадагы багланышларның төп юнәлешләре һәм формалары Үзара арадашлык һәм мәгълүмат алмашу Үзара уңышлы багланышлар балалар бакчасы бала гаиләсенең тәрбия мөмкинлекләре белән таныш, ә гаилә баланы тәрбияләү ышанып тапшырыл- ган мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында хәбәрдар булган очракта гына урнашырга мөмкин. Бу багланышлар бала үсешендә бер-береңә кирәкле ярдәм күрсәтергә, тәрбияләүдә гомуми мәсьәләләрне хәл итү өчен булган педагогик ресурсларны тартырга мөмкинлек бирә.

Тәрбия потенциалын ике яклап тирәнтен аңлау өчен әңгәмәләр уздыру, анкеталар төзү, иншалар язу белән бергә махсус оештырылучы социаль-педагогик диагностика; педагогларның тәрбияләнүчеләр гаиләләрендә бу- лулары; балалар бакчасында ачык

ишекләр көннәре оештыру; балаларны тәрбияләүче якларның казанышлары һәм кыенлыклары белән танышуга юнәлтелгән төрле җыелыш-очрашулар зур әһәмияткә ия.
Беренче җыелыш-очрашуларның максаты — педагогларның гаиләләр белән һәм тәрбияләнүчеләр гаиләләренең үзара, гаиләләрнең педагоглар белән төрле яклап танышуы. Аралашудагы киртәләрдән арыну өчен, ата- аналарда уңай эмоцияләр тудыручы, педагоглар белән ышанулы мөнәсәбәт- ләр үстерүгә юнәлтелгән махсус алымнар («Дистанция сайла», «Ассоциацияләнгән рәт», «Фотосурәтләр теле», «Туктаусыз сөйләшү» һ.б.) куллану артык булмас. Шундый җыелышларны ел дәвамында уздыру, һәр җыелышта үз мәсьәләләреңне хәл итә бару урынлы. Тәрбияләүче өлкән кешеләрнең бер-берләренә даими рәвештә балалар- ның балалар бакчасындагы һәм гаиләдәге тормышыннан төрле фактларны, һәм кәефе, эчке һәм тышкы халәте, үзен ничек хис итүе, балалар — өлкәннәр (шул исәптән балалар — ата-аналар) мөнәсәбәтләре турында хәбәр итеп торулары зарур. Әлеге хәбәрләшү турыдан-туры аралашу аша (әңгәмәләр, консульта- цияләр барышында, җыелышларда, конференцияләрдә) яки читләтеп, төрле чыганаклардан — стендлардан, газеталардан, журналлардан (кулдан язып, электрон чыганакта), гаилә календарьларыннан, төрле буклетлардан, интер- нет-сайтлардан (балалар бакчасы, мәгариф идарәсе органнары сайтларын- нан) мәгълүмат алу, шулай ук язышу (шул исәптән электрон чыганаклар аша) нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла.
Стендлар. Стендларда стратегик (күпьеллык) һәм тактик (еллык) мәгълүмат урнаштырыла. Стратегик мәгълүматка балалар бакчасы үсешенең ерак һәм уртача перспективага исәпләнгән максатлары, гамәлгә ашырылучы белем бирү программасы, мәктәпкәчә учреждениенең инновацион проектлары, шулай ук белем бирү буенча өстәмә хезмәтләр турындагы хәбәрләр керә. Тактик мәгълүматлар педагоглар һәм аларның графиклары, көндәлек режим, төркемдә бер елга исәпләнгән тәрбия-белем бирү эшенең бурычлары һәм эчтәлеге турындагы хәбәрләрне үз эченә ала.
Тәрбияләүче өлкәннәрнең зур кызыксынуын тудыручы оператив стенд мәгълүматларына төркемдә (балалар бакчасында, районда) көтелә торган яки булып узган вакыйгалар: акцияләр, конкурслар, репетицияләр, күргәзмәләр, очрашулар, уртак проектлар, ял көннәрендәге экскурсияләр һ.б. турындагы хәбәрләр керә.
Мәгълүматның бу төре тиз искергәнгә күрә, аны даими рәвештә яңартып торырга кирәк. Стенд мәгълүматлары, әгәр аларны әзерләүдә ата-аналар катнашса, ул мәгълүматлар гаиләнең хәбәрләр җәһәтендәге мәнфәгатьләренә җавап бирсә, алар структура буенча уңышлы урнашсалар һәм эстетик яктан уңыш- лы бизәлсәләр (фотосурәтләр һәм иллюстратив материал кулланыла), ата- аналарда күбрәк кызыксыну уята. Мәгълүмат (бигрәк тә оператив мәгълүмат) тәрбияләүче өлкәннәргә үз вакытында барып ирешсен өчен, аны балалар бакчасы сайтында, шулай ук гаилә календарьларында кабатлау мөһим.

| Ай | Эш төре |
|---|---|
| сентябрь | Ата-аналар җыелышында катнашу (уртанчылар, зурлар, мәктәпкәчә төркеме). |
| | Һәр төркемдә ата-аналар өчен күрсәтмә материалларны яңарту. |
| октябрь | Җыр һәм шигырьләрне өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |

| | |
|---|---|
| ноябрь | Ата-аналар өчен анкета. |
| декабрь | “Моны белү кызыклы” татарча журналлар уку. |
| | Яңа елга күренеш өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |
| январь | Һәр төркемдә ата-аналар өчен күрсәтмә материалларны яңарту. |
| февраль | “Минем яраткан мультфильм герое”, ата-аналар берлектә рәсем күргәзмәсе. |
| март | 8 мартка күренеш өйрәтүдә ата-аналарның ярдәменә таяну. |
| | “Нәүрүз” бәйрәменә чакыру. |
| апрель | Г.Тукай әсәрләре буенча кул эшләре күргәзмәсе оештыру “Әкиятләр илендә”. |
| | Ата-аналар өчен анкета. |
| май | “Минем гаиләм” фотокүргәзмә. |

**3.1. Психолого-педагогик эш эчтәлеге.**

Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр).

Танып белү-сөйләм үсеше.

«Танып белү» белем бирү өлкәсе

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларынбилгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл) исемнәренәйтергә өйрәтү. Әйләнә-тирә (шәһәр яки авылның төп объектлары), янәшәдәге предметлар, аларның билгеләнешләребелән таныштыруны дәвам итү. Кешеләр яши торганйортларның төзелеше, өй кирәк-яраклары турындагы күзаллауларын үстерү.

Балалар бакчасында, өйдә була торган вакыйгаларда (бәйрәм иртәләрендә, якын кешеләренең һәм яшьтәшләренең туган көннәре һ.б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә, гаилә бәйрәмнәрендә катнашу һ.б.) актив катнашасы килү теләгеуяту.Үз-үзләрен кунакта, дусларының туган көннәрендә, халык бәйрәмнәрендә, балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Урамда, юлларда, җәмәгать транспортында тәртип кагыйдәләре белән таныштыру.Балаларда ял (бәйрәм) көннәрен кем белән, кайда (циркта, «Кырлай» аттракцион паркында, үзәк мәйданда, шәһәр урамнарында, шәһәрдән читтә) үткәрүләре турында сөйләргә теләк уяту. Вакыйгаларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт чагылышын, алган тәэсирләрен өлкәннәр һәм балалар белән бүлешүгә омтылышларын хуплау.Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар (каен, имән,чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк атучы үлән үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы), бүлмә гөлләре (яран,фикус) белән таныштыру. Бөҗәкләр (күбәләк, камка, энә карагы) турындагы күзаллауларын киңәйтү.Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар,аларның үзенчәлекләре белән таныштыру эшен дәвам итү.Хайваннар дөньясына, барлык тереклек ияләренә, табигатькәкарата кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше һәм ттабигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыллары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү.Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына (салават күпере, агачлардагы бәс, беренче чәчәкләр күренү һ.б.га) соклана белүкүнекмәләре үстерү.

«Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе

«Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәгекешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чараларын үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтеләһәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, аралашырга өйрәтү; күргәннәре турында күзаллап сөйләргәгенә түгел, тормышында булган вакыйгалар, башкарган эшгамәлләре, үзен кызыксындырган күренеш һәм предметлар,туган як табигате объектлары турында да сөйләргә күнектерү.Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. Үз фикерләрен әйтү,үтенеч һәм тәкъдимнәр белән өлкәннәргә мөрәҗәгать итү омтылышларын хуплау.Таныш булган татар халык әкиятләреннән өзекләр,шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү; 2–3 җөмләдән торган хикәяләр төзергә өйрәтү. Җөмләдәге сүзләрне дөрес бәйләр өчен, кушымчаларны дөрес файдаланырга өйрәтү. Балаларның уен барышында үзара мөнәсәбәтләрен (уендагы үзләренең эш-гамәлләре турында сөйлиләр, уенчыклар, аларны алмаштыручы предметларны сүзләр белән атыйлар) җайга салырга булышу. Балаларның сөйләмен барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү өчен кирәкле сүзләр белән баету. Татар телендәге авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, аваз культурасы тәрбияләү.

Сөйләм үстерүгә балаларның яшьтәшләре белән бергәләп тәрбиячене̦ң сәнгатьле уку якисөйләмен тыңлау ярдәм итә.Татар халык әкиятләрендә, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәби әсәрләрендә вакыйгалар барышын күрсәтмәлелек (уенчыклар,рәсемнәр, хәрәкәтләр) ярдәмендә күзәтергә, аларның эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишаләләр белән белдерергә өйрәтү. Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, персонажларга үз мөнәсәбәтен белдерергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү. Әдәби әсәрләргә карата хисле кичерешләр булдыру, әдәби сүзгәкызыксыну уяту.Китаптагы иллюстрацияләрне караганда, әдәби әсәр геройларын һәм аларның гамәлләрен танырга булышу. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (юаткычлар, әйтемнәр, бармак уеннары) белән таныштыру. Кече фольклор формаларын көндәлек тормышта куллануны хуплау.

Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр).

Психолого-педагогик эш эчтәлеге.Танып белү-сөйләм үсеше.

«Танып белү» белем бирү өлкәсе

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирүбурычларынбилгели.Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл), республика исемнәрен әйтергә өйрәтү. Шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары турында сөйләү. Туган шәһәрдә (авылда) булган вакыйгалар турында әңгәмәләрдә ешрак катнашу тәҗрибәсе туплауларына ирешү. Туган як образлары белән бәйле буклетлар, журналлар, рәсемле китаплар, альбомнар, истәлекле урыннарда гаилә белән төшкән фотосурәтләр, значоклар, открыткалар җыелмасы тупларга теләк тудыру.

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү. Кешенең хуҗалык эшчәнлеген – үзе, тору урыны, йорт хайваннары һәм үсемлекләр, ишегалдының, урамының чисталыгын – кайгыртуы турында беренче

күзаллаулар формалаштыру. Шәһәр (авыл) урамнарын, торак йортларны тәртиптә тотарга теләк тудыру. Бирелгән урынның кайбер үсемлекләре: агачлар (нарат, өрәңге), бүлмә гөлләре (бальзамин, фуксия), гөмбәләр (ак гөмбә, майлы гөмбә, баллы гөмбә), җимешләр (алма, слива), яшелчәләр (кыяр, помидор, суган, кишер, шалкан), җиләкләр (кура җиләге, миләш, чия, карлыган) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәргә җиләк-җимеш, яшелчәләр уңышын җыяргa булышу теләге тудыру. Бөҗәкләр (кырмыска, умарта корты, коңгыз, шөпшә) турындагы күзаллауларын баету; кыргый һәм йорт хайваннары, төркемдәге табигать почмагында яшәүчеләр белән танышуны дәвам итү. Балалар бакчасындагы участокка очып килүче кошларны (чыпчык, кызылтүш, песнәкне) күзәтү оештыру, аларны ел буена өстәмә ашатырга теләк уяту. Балаларның кырда, урманда, елгада күргәннәрен сөйли алуларына ирешү. Үзләренә ошаган үсемлек, хайван, табигать почмагының рәсемен ясарга, фотога төшерергә омтылыш тәрбияләү.

«Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе

Тирә-юньдәге әйберләр һәм вакыйгалар турында аңлату ярдәмендә балаларның сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру.

Әйберләрнең кайда, ничек урнашуларын (уңда, сулда, югарыда, түбәндә,...янында), тәүлекнең кайсы вакыты булуын (иртә, көндез, кич, төн), кешеләрнең халәтен (шатлану, күңелсезләнү, үпкәләү) белдерә торган сүзләрне әйтү һәм сөйләгәндә куллана белү күнекмәләре бирү.

Сөйләшкәндә әйберләрнең өлеш-кисәкләренең исемнәрен әйтеп, аларның үзенчәлеген белдерә торган сыйфатларны, рәвешләрне һәм кушымчаларны дөрес кулланып сөйләргә өйрәтү.

Йорт жиһазлары, яшелчә, җиләк-җимеш, хайваннар кебек гомуми төшенчә белдерә торган сүзләрне аңларга һәм сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү

Балаларның артикуляция аппаратын камилләштерү, фонематик ишетү сәләтләрен үстерү, авазларны дөрес әйтү юнәлешендә кечкенәләр төркемендә башланган эшне дәвам иттерү. Артикуляция гимнастикасы ясау.

Кечкенәләр  төркемендә дөрес әйтергә өйрәнелгән а-ә, у-ү, о-ө, и-ы сузыкларының һәм м, н, б, п, т, к, г тартыкларының әйтелешен кабатлау.  Шул авазларны кертеп сүзләр уйлау, шул сүзләрне кертеп кыска җөмләләр төзетү.

Сүзләрдәге  аерым авызларга басым ясатып, аларны ачык һәм дөрес әйттерү күнегүләре эшләтү (Аза-т;  а-ттт;  баа-л;  ба-ллл;  бааа-с;  ба-ссс;  ба-са;  а-на).

Э-е сузыкларын, з, с, ф, в, ш, ж, л, җ тартыкларын дөрес әйтергә өйрәтү. Шул авазарны кертеп, сүзләр әйттерү. Сүзләрне әйткәндә аерым авазларга  басым ясату.

Й, е, я, ю авазлары белән башланган сүзләрне, җ авазы белән алмаштырмыйча, чиста әйтергә өйрәтү (йорт, йон, йомыш, йөк, йөри, йөрәк, ел, елга, елан, юан, юмарт, юкә); къ, гътартыкларын нечкәртмичә әйтргә, в авазының татарча сүзләрдә  үзенчәлекле әйтеешен сакларга, балаларның телләрендә еш кулланыла торган чит телдән кергән сүзләрне (вагон, винегрет, дача, завод, концерт, монтер, поезд, трамвай, шофер) дөрес кулланырга уүнектерү; сөйләмнең нормаль темпын булдырырга, сөйләгәндә ашыкмаска өйрәтү.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтүдә төрле уеннардан, дидактик материаллардан файдалану. Теге яки бу аваз ешрак кабатлана торган шигырьләрне, тизәйткечләрне аерым – аерым һәм бергәләп әйттерү, кайберләрен ятлау.
Авазларны һәм сүзләрне, шул аваәлар һәм сүзләр кергән җөмләләрне балаарның ачык тавы белән дрес итеп әйтә белүләрен ирешү.
Сөйләмнең грамматик төзелеше
Җөмләләрдә сүзләрне дөрес кулланырга өйрәтү. Гади сүзләргә күплек (лар-ләр) һзм тартык кушымчаларын ялгарга (әнием, әтием); сыйфат һәм фигыльләр кулланып, гади җөмләләр төзергә өйрәтү.
Сөйләмдә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең иң гади төрләрен кулланырг өйрәтү.
Бәйләнешле сөйләм үстерү
Балаларның диалогик сөйләмен камилләштерүне дәвам иттерү. Әңгәмәләргә катнашырга өйрәтү; сораулар бирү, үзләреннән сораулар бирдертү, бирелгән сорауларга җавап кайтара белергә өйрәтү. Сөйләшкәндә сүзләрне ачык һәм башкалар аңларлык итеп әйтергә күнектерү, төгәлләнгән җөмләләр белән сөйләшергә гадәтләндерү.
Ишеткән, укылган кыска хикәя һәм әкиятләрнең эчтәлеген сөйләргә өйрәтү. Күзәткән әйбер турында, сюҗетлы рәсемнәрнең этәлеге буенча кечкенә хикәяләрен төзергә өйрәтү.
Матур әдәбият уку балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыр максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирүбурычларын билгели.
Әдәби әсәрләрнең төрле жанр һәм тематикасын – халык әкияте, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя, шигырьләрен, шигъри фольклорның кече формаларын тыңлау, аларның эчтәлегенә хисләрен белдерү сәләтен үстерү.
Әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыкта булган хәлләр, балалар һәм өлкәннәр эшләгән эшләр турындагы күзаллаулар ярдәмендә баланың эчке дөньясын баету, укыганны аңлар өчен сораулар бирү һәм фикер алышу.
Тәрбияче ярдәмендә татар әкиятләреннән өзекләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.
Укыган әсәрдән аеруча кызыклы, сәнгатьле өзекләрне кабатлаганда, балаларга сүзләрне һәм катлаулы булмаган фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.
Кечкенә күләмле шигырьләрне, шигъри фольклорның кече формаларын яттан сөйләүләрен хуплау.
Зурлар төркеме(5 яшьтән 6 яшькә кадәр).
Психолого-педагогик эш эчтәлеге. Танып белү-сөйләм үсеше.
«Танып белү» белем бирү өлкәсе
«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда таныпбелү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.
Татарстан – күпмилләтле республика. Казан – эре промышленность үзәге, Россиянең борынгы шәһәрләреннән берсе. Казан – республиканың һәм бөтендөнья татарларының башкаласы. Казанда Президент, Татарстан Хөкүмәте һәм шәһәр мэрыэшлиләр. Шулар турында балаларда күзаллаулар булдыру.Балаларга туган як турында мифлар, легендалар, тарихларсөйләү. Туган шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары,

биккүптәнге вакыйгалары, тарихи истәлекләре, музейлары, урамнары белән таныштыру.
Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб,гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкыңның бер өлешебулуларын аңлату.
Татарстан Республикасының географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама һәм Идел елгаларын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү).
Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Милли бәйрәмнәр (Нәүрүз бәйрәме, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ. б.) турында күзаллаулар булдыру. Башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү.Милли һәм бөтендөнья культураларының үткәне һәм бүгенгесе белән танышуга тарту. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең (шагыйрьләр: Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ. б., язучылар: А. Алиш, Р. Батулла һ. б., рәссамнар: Х. Якупов, Х. Казаков һ. б., скульптор Б. Урманче һ. б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру. Аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксыну уяту.
Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү. Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән таныштыру. Идел-Кама дәүләт тыюлыгы, «Түбән Кама» миллипаркы, республиканың табигатен саклауда аларның әһәмияте турында сөйләү. Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип карау ярамаганлыгын аңлату, аны файдалануның беренчел күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару үләннәрен тамырлары белән җыйса...»).
Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзенчәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә өйрәтү(ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; урман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр,бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары,кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.).
Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рәвешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлешләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын (шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су хайваннарының, сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарны тавышларыннан танырга булышу.Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләрбайлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү.
«Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе
Балаларның сөйләмен үстерүне дәвам иттерү, барлык авазларны да дөрес һәм ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, монологик сөйләмнең гади төрләренә өйрәтү.
Сорауларга ашыкмыйча, башкалар ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирергә күнектерү.
Балаларның сүзлеген ташчы, балта остасы, тракторчы, комбайнчы, савымчы, кием тегүче, терлекче һөнәрләрен аңлата торган сүзләр; трактор, экскаватор, күтәрү краны, комбайн, тырма, чәчкеч; тузан суырткыч, суыткыч кебек техника атамалары; кызыл, зәңгәр, сары, якты, караңгы, тәмле, каты, йомшак кебек сыйфатлар; тырыш, җитез,

уңган, оста, батыр кебек рәвешләр; кешенең эш хәрәкәтен, хезмәт эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр исәбенә баету һәм кулланышка кертү. Мәгънәдәш (синоним) сүзләр куллану буенча күнегүләр ясау.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү буенча алдагы елларда башланган эшне дәвам иттерү, фонематик ишетү сәләтләрен үстерү, артикуляция аппаратын формалаштыру юнәлешендә даими эшләү.

Теге яки бу авазның ясалышында катнаша торган органнар турында төшенчә бирү, ул авазларның сүзләрдә һәм сөйләмдә әйтелешен ныгыту буенча күнегүләр башкару.

Балаларның алдагы елларда (төркемнәрдә) өйрәнгән ә, у, ү, о,ө, ы, э сузыкларын, м, н, л, ң, б, п, т, ч, д, к, г, з, с, ф, ш, ж тартыкларын дөрес итеп әйтә белүләренә ирешү.

Татар теленә генә хас булган ә, ө, ү, җ, ң, һ авазларын, шулай ук с-з, с-ц, ш-ж, җ-з, л-р һ.б. еш бутап әйтелә торган авазларны ишетеп аера белергә өйрәтү, ачык һәм дөрес итеп әйтә алуларына ирешү.

Сөйләмнең грамматик төзелеше

Балаларны җөмләдә ия белән хәбәрне һәм җөмләнең башка кисәкләрен яраштырып сөйләргә, берлек сандагы сүзләрне күплек формасына әйләндерә белергә өйрәтү.

Алмашлыклар турында төшенчә бирү. Исемнәрне алмашлыклар белән алыштыру буенча күнегүләр (Гөлназ судан кайта. Ул судан кайта.) башкару.

Балаларның җөмләдәге һәр сүзне үз урынына куеп, кушымчаларны дөрес ялгап сөйли белүләренә ирешү.

Сөйләшкәндә, хикәяләр сөйләгәндә, әңгәмәләрдә исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәләрен белдерүче кушымчалардан файдаланырга өйрәтү (авылдаш, якташ, печәнлек, ташлык, тайгак, алсу, сап-сары, зәп-зәңгәр).

Сөйләмдә гади һәм кушма җөмләләр кулланырга өйрәтүне дәвам итү. Әкиятләрне ролҗләргә бүлеп укыганда, геройларның кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияне үзгәртеп, кирәкле урында пауза ясап сөйләү күнекмәләре бирү.

Бәйләнешле сөйләм үстерү

Балаларның диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү юнәлешендә эшләү: иптәшләре белән үзара тыныч, ягымлы итеп сөйләшә белергә, башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәтү. Сораулар бирергә, тәрбияче һәм балалар биргән сорауларга төгәл, һәркем ишетерлек һәм аңлarлык итеп җавап бирергә күнектерү.

Күләме зур булмаган әдәби әсәрләрне (әкият, хикәяләр), тәрбияче сорауларыннан башка, бәйләнешле, эзлекле һәм сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү.

Персонажларның кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияне үзгәртеп, кирәкле урында пауза ясап, сөйләргә өйрәтү.

Балаларны, билгеле бер әйбер турында яки рәсемнәргә карап, тәрбияче үрнәгендә яки бирелгән план нигезендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. Үзенә таныш вакыйгалар турында тулы җөмләләр белән сөйли белергә, тәрбияче тәкъдим иткән тема буенча зур булмаган хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү.

Матур әдәбият уку балада китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларны танып белү әдәбиятына һәм матур әдәбиятка,халык авыз иҗатына тарту, әдәби кичерешләр байлыгын формалаштыру.

Китапның белем чыганагы икәнлегенә төшендерү. Китапка сакчыл караш тәрбияләү, мөстәкыйль рәвештә китапның рәсемнәрен карарга, эчтәлеген яңадан тыңларга теләк уяту. Зур булмаган проза текстларының эчтәлеген ачып бирә белергә һәм кечкенәрәк шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләргә, текстларны рольләргә бүлеп укуда, әсәрләрне сәхнәләштерүдә катнашырга өйрәтү.
Татар халык мәкаль-әйтемнәре белән таныштыру, аларның мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Балаларның иҗат чагылышлары, иҗат итү башлангычлары өчен (күрсәтмә материалга нигезләнелгән такмазалар, юаткычлар, хикәяләр) шартлар тудыру.
Балаларга әкиятләрнең (шулай ук татар халык әкиятләренең) жанр үзенчәлекләрен аңлатуны дәвам итү. Әкият геройларының эш-гамәлләренә бәя бирергә теләк уяту, аларның үз-үзен тотышларындагы яшерен мотивларны аңларга булышу.
Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр).
Психолого-педагогик эш эчтәлеге.
Танып белү-сөйләм үсеше. «Танып белү» белем бирү өлкәсе
«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.
Республиканың үткәне һәм бүгенге яшәеше, урнашу урыны, табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү. Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык, һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру. Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә өйрәтү. Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы, культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү.
Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (балалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү)күрә белергә өйрәтү.
Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы,татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, сәүдә белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү.
Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өйрәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый белергә ярдәм итү. Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенгесенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев,Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров, Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов, К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр актёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә кызыксыну уяту. Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчәнлекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс, И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерү, Казан (Идел буе) федераль университеты укытучылары һәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү.
Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.). Әти-әниләрне балаларга әби һәм бабаларының сугышта алган бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелискларга чәчәкләр кую һ. б.).
Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирәнәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру.
Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклек ияләре, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек (флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәкочрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның аңнарына җиткерү.
Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләр белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тоткан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын чиста тотарга теләк уяту. Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төсмуллыгына игътибар итү.
Табигатьтәге үзгәрешләрне күрәбелергә өйрәтү.

«Сөйләм үстерү» белем бирү өлкәсе
“Мәктәпкә әзерлек програмасы”ның “Туган телебезне өйрәнәбез” бүлегендә эшчәнлек әзерләү һәм үткәрү барышында балаларны грамоталылык нигезләрен үзләштерү эшенә актив әзерләү алып барыла. Педагог максатчан рәвештә балаларны тәкъдим ителгән һәр сүзгә аваз анализы ясарга: сузык авазларны, калын һәм нечкә әйтелешле тартык авазларны аера белергә, теге яки бу сүзне барлыкка китергән авазлар рәтенә ориентлашырга, бирелгән модельләргә туры китереп сүзләр сайларга өйрәтә.
Сүзләргә аваз анализы ясау: .
Матур әдәбият уку балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштырмаксатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Әдәби, танып белү, энциклопедик характердагы китаплар ярдәмендә уку эшчәнлеген киңәйтү. Әкият, хикәя, шигырьнең төп билгеләре белән таныштыру. Укыганны аңлый, әдәби геройларның эш-гамәлләрен дөрес бәяли, булган вакыйгалар турында үз фикереңне әйтә белергә өйрәтү.
Кайбер проза текстларының эчтәлеген сәнгатьле итеп һәм кечерәк шигырьләрне яттан сөйләргә өйрәтү, татар халык әкиятләрен сәхнәләштерүдә катнашырга теләк тудыру.
Идел буе халыкларының әкиятләрен файдаланып, әдәби образны үзләре аңлаганча күзаллау нигезендә, балаларның иҗади хыялларын үстерү.
Кече фольклор жанрына карата кызыксыну булдыру. Балаларны, үз әдәби тәҗрибәләреннән чыгып, стиль һәм жанр үзенчәлекләрен саклап, сүз сәнгатенә якынайту.
Татар халык юморы белән таныштыру. Юмор хисе үстерү.

3.2. Предметлы-үстерелешле әйләнә тирәлек

Мохит төшенчәсе астында табигый, социаль-көнкүреш һәм (яки) мәдәни-эстетик характердагы тирәлек күздә тотыла. Бу — кешенең яшәеш шартлары, аның тормыш даирәсе. Мохит махсус проектлана торган юнәлеш алырга мөмкин, һәм бу очракта аның турында шәхесне формалаштыручы мөһим фактор — белем бирү тирәлеге буларак карау күзәтелә. Балалар бакчасында белем бирү мохите баланың мәктәпкәчә балачагын тулы кыйммәтле уздыру өчен кирәкле махсус шартларны таләп итә. Предметлы үсеш мохите дигәндә баланың танып белүдә, аралашуда, хезмәт, тулаем физик һәм рухи үсеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җайлаштырылган, оештыру ягыннан формалаштырылган һәм предметлар белән тулыландырылган билгеле бер тирәлек аңлана. Үсешкә булышлык итүче предметлы мохитне заманча күзаллау баланың актив эшчәнлеген тәэмин итүне, аның субъектив позициясен формалаштыруны, иҗади сәләтләрен, мөмкинлекләрен барлык чаралар белән үстерүне үз эченә ала. Мохит оештыруга төп таләпләр
Мәктәпкәчә оешманың үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите:
• тулы эчтәлекле, үсешкә илтүчән;
• үзгәрүчән;
• күп функцияле;
• вариатив;
• аңлаешлы;
• куркынычсызлыкны тәэмин итүчән;
• сәламәтлекне саклаучан;
• эстетик җәлеп итүчән булырга тиеш.

3.4. Материаль - техник яктан тәэмин ителеш

| | | |
|---|---|---|
| Татар теле кабинеты | Белем бирү эшчәнлеге, индивидуаль, коррекцион эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр, ачык эшчәнлекләр . | Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, принтер, экран, ноутбук, магнитофон, курчак театры өчен уенчыклар, дидактик һәм интерактив уеннар, тематик папкалар, укыту -методик комплект (күрсәтмә һәм таратма материал, аудио-, видео- дисклар, маскалар),ТР һәм РФ символикасы. |

3.6. Белем бирү эшчәнлеген оештыру.

**“Туган телдә сөйләшәбез” (авторлар: Хәзрәтова Ф.В., З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина.- Казан, ТКН, 2012) укыту-методик комплекты буенча беренче кече яшьтәгеләр төркемендә (2-3 яшь) 2023-2024 нче уку елына режим вакыты өчен эш планы(икенче вариант).**

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Танышу** | Танышу. | 1 | 5.09.23 |
| 2. | **Безнең балалар бакчасы** | Аю белән куян кунакка килгән. | 1 | 6.09.23 |
| | | Куянга өй төзибез. | 1 | 7.09.23 |
| | | “Курчагым | 1 | 12.09.23 |
| | | “Үчтеки, үчтеки” такмагын уку | 1 | 13.09.23 |
| | | Курчакның туган көне. | 1 | 14.09.23 |
| | | Карусельгә сәяхәт. | 1 | 19.09.23 |
| | | Минем матур тубым. | 1 | 20.09.23 |
| | | Әминә Бикчәнтәеваның “Туп-туп, тубыбыз” шигырен уку | 1 | 21.09.23 |
| | | Уенчыклар кибетендә. | 1 | 26.09.23 |
| 3. | **Көз** | Көз җитте. | 1 | 27.09.23 |
| | | Көзге яфраклар. | 1 | 28.09.23 |
| | | ”Безнең Алсу “ сериясеннән рәсем карау. | 1 | 3.10.23 |
| | | Яшелчәләр. | 1 | 4.10.23 |
| | | Куян кунакка килгән. | 1 | 5.10.23 |
| | | “Шалкан” әкияте . | 1 | 10.10.23 |
| | | Җиләк-җимешләр. | 1 | 11.10.23 |
| | | Әбидә кунакта. | 1 | 12.10.23 |
| | | Яшелчә бакчасында. | 1 | 17.10.23 |
| 4. | **Мин – дөнянең бер кешесе** | Минем исемем бар. | 1 | 18.10.23 |
| | | Бу — мин. | 1 | 19.10.23 |
| | | Мин –дөньяның бер кешесе. | 1 | 24.10.23 |
| 5. | **Гаилә.** | Минем гаиләм. | 1 | 25.10.23 |
| | | Безнең гаилә. | 1 | 26.10.23 |
| | | Әйдәгез, дуслашыйк. | 1 | 31.10.23 |
| | | Бу өйдә кем яши?. | 1 | 1.11.23 |
| | | Без чәбәкәй итәбез. | 1 | 2.11.23 |
| | | “Уйнарга яратабыз” | 1 | 7.11.23 |
| | | “Гаилә” рәсемен карау. | 1 | 8.11.23 |
| | | Шәйхи Маннурның “Яратам” шигырен уку. | 1 | 9.11.23 |
| | | “Әйдәгез уйныйбыз”. | 1 | 14.11.23 |
| 6. | **Кыш** | “Ап-ак кар ява” шигырен уку. | 1 | 15.11.23 |
| | | “Алсу урамга җыена”. | 1 | 16.11.23 |
| | | “Кар бабай ясау”. | 1 | 21.11.23 |
| | | “Кыш” рәсемен карау. | 1 | 22.11.23 |
| | | “Кар ява”. | 1 | 23.11.23 |
| | | А.Алишның “Куян кызы” әкияте. | 1 | 28.11.23 |
| 7. | **Яңа ел бәйрәме** | Яшел чыршы. | 1 | 29.11.23 |
| | | Әминә Бикчәнтәеваның “Беренче адым” шигырен уку**.** | 1 | 30.11.23 |
| | | “Чыршы бизибез”. | 1 | 5.12.23 |
| | | “Куян чыршы янында” темасы буенча сөйләшү. | 1 | 6.12.23 |
| | | Купшы чыршы. | 1 | 7.12.23 |
| | | Без музыка залында. | 1 | 12.12.23 |
| 8. | **Минем әйләнә-тирәм** | Яраткан уен бүлмәбез. | 1 | 13.12.23 |
| | | Алсу бүлмәсе. | 1 | 14.12.23 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Безнең урам. | 1 | 19.12.23 |
| | | Безнең апа. | 1 | 20.12.23 |
| | | Алсу авырган. | 1 | 21.12.23 |
| | | Алсу кунакта. | 1 | 26.12.23 |
| | | Безнең йортта нәрсәләр бар? | 1 | 27.12.23 |
| | | Йорт кошлары. | 1 | 28.12.23 |
| | | Хайваннарны чакыру . | 1 | 9.01.24 |
| | | “Маэмаем”. | 1 | 10.01.24 |
| | | М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку. | 1 | 11.01.24 |
| | | “Гав исемле песи баласы”. | 1 | 16.01.24 |
| | | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку. | 1 | 17.01.24 |
| | | “Чуар тавык” әкияте. | 1 | 18.01.24 |
| | | Әкияттә кунакта. | 1 | 23.01.24 |
| 9. | **Әтиләр-бабайлар** | Зур гаилә. | 1 | 24.01.24 |
| | | Безнең әтиләр һәм абыйлар. | 1 | 25.01.24 |
| | | Бабайга кунакка барабыз. | 1 | 30.01.24 |
| | | “Машина”. | 1 | 31.01.24 |
| | | “Самолёт”. | 1 | 1.02.24 |
| | | “Булатның машинасына гараж ясау”. | 1 | 6.02.24 |
| 10. | **Әниләр-әбиләр** | “Кибеткә бару”. | 1 | 7.02.24 |
| | | “Әбидә кунакта”. | 1 | 8.02.24 |
| | | “Безнең әниләр”. | 1 | 13.02.24 |
| | | “Алсуны табибка алып барабыз”. | 1 | 14.02.24 |
| | | “Табибка барабыз”. | 1 | 15.02.24 |
| | | “Курчакны йоклату”. | 1 | 20.02.24 |
| 11. | **Халык иҗаты** | “Хайваннарны чакыру”. | 1 | 21.02.24 |
| | | “Йомры икмәк” рус халык әкияте. | 1 | 22.02.24 |
| | | “Шалкан” әкиятен уку. | 1 | 27.02.24 |
| | | “Авылда”. | 1 | 28.02.24 |
| | | “Теремкәй” рус халык әкиятен уку. | 1 | 29.02.24 |
| | | “Өч аю”. | 1 | 5.03.24 |
| 12. | **Яз** | “Урамда яз”. | 1 | 6.03.24 |
| | | “Яз җитә”. | 1 | 7.03.24 |
| | | “Яз.” | 1 | 12.03.24 |
| | | “Җәнлекләр урманда яшиләр”. | 1 | 13.03.24 |
| | | “Язгы урманда”. | 1 | 14.03.24 |
| | | “Күңелле ял итәбез”. | 1 | 19.03.24 |
| | | “Агачлар”. | 1 | 20.03.24 |
| | | “Каргалар”. | 1 | 21.03.24 |
| | | “Без уйныйбыз”. | 1 | 26.03.24 |
| | | “Яз килде”. | 1 | 27.03.24 |
| | | Аваз культурасы “А, Ә” авазы. | 1 | 28.03.24 |
| | | “Акбай һәм Мияу” анимацион сюжет. | 1 | 2.04.24 |
| 13. | **Җәй** | Бүлмә гөлләре | 1 | 3.04.24 |
| | | “Бүлмә гөлләре. Кабатлау.” | 1 | 4.04.24 |
| | | Мульфильмда кунакта. | 1 | 9.04.24 |
| | | “Саф һавада”. | 1 | 11.04.24 |
| | | “Чәчәкләр”. | 1 | 16.04.24 |
| | | “Балалар бакчасы  ишегалдында”. | 1 | 17.04.24 |
| | | “Экология сукмагы буенча сәяхәт?”. | 1 | 18.04.24 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | “Су белән уен”. | 1 | 23.04.24 |
| | | “Чәчәкләр. Кабатлау”. | 1 | 24.04.24 |
| | | Тузганак чәчәген карау. | 1 | 25.04.24 |
| | | Ә.Кариның “Чебиләр” шигыре. | 1 | 2.05.24 |
| | | Зоопарк. | 1 | 3.05.24 |
| | | “Күңелле ял итәбез. Кабатлау.”. | 1 | 7.05.24 |
| | | “Рәхмәт, җәй!”. | 1 | 8.05.24 |
| | | “Күңелле уеннар”. | 1 | 14.05.24 |
| | | “Тук, тук, тукран” эндәшен уку. | 1 | 15.05.24 |
| | | “Кояш чык, чык!” эндәшен уку. | 1 | 16.05.24 |
| | | “Тавык һәм чебиләр” рәсеме буенча эш. | 1 | 21.05.24 |
| | | Мульфильмда кунакта. | 1 | 22.05.24 |
| | | “Күңелле уеннар”. Кабатлау. | 1 | 23.05.24 |

**“Туган телдә сөйләшәбез” (авторлар: Хәзрәтова Ф.В., З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина.- Казан, Фолиант, 2013) укыту-методик комплекты буенча икенче кече яшьтәгеләр төркемендә (3-4 яшь) 2023-2024 нче уку елына режим вакыты өчен эш планы(икенче вариант).**

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Исәнме, балалар бакчасы** | “Танышу” | 1 | 5.09.23 |
| | | “Өйдә кем яши?” | 1 | 6.09.23 |
| | | “Мин малай, мин кыз” . | 1 | 7.09.23 |
| | | “Мияу белән танышу”. | 1 | 12.09.23 |
| | | “Әйдәгез, танышыйк”. | 1 | 13.09.23 |
| | | “Әйдәгез, дуслашыйк”. | 1 | 14.09.23 |
| 2. | **Уенчыклар** | “Минем яраткан уенчыкларым”. | 1 | 19.09.23 |
| | | “Карусельгә сәяхәт” | 1 | 20.09.23 |
| | | Без уйнарга яратабыз”. | 1 | 21.09.23 |
| | | “Йомшак уенчык карау” . | 1 | 26.09.23 |
| | | “Туп” | 1 | 27.09.23 |
| | | “Туган көн” | 1 | 28.09.23 |
| | | “Мияу кунакка килгән” | 1 | 3.10.23 |
| | | “Уенчыклар кибете” | 1 | 4.10.23 |
| 3. | **Көз** | Алтын көз. | 1 | 5.10.23 |
| | | Көз килде. | 1 | 10.10.23 |
| | | Аваз культурасы, Ө авазы. | 1 | 11.10.23 |
| | | Куян үстергән кишер һәм помидор. | 1 | 12.10.23 |
| | | Яшелчә бакчасында. | 1 | 17.10.23 |
| | | “Шалкан” әкияте. | 1 | 18.10.23 |
| | | Җиләк-җимеш бакчасында. | 1 | 19.10.23 |
| | | Бакчада алмалар өлгерде. | 1 | 24.10.23 |
| | | Уйный-уйный саныйбыз. | 1 | 25.10.23 |
| 4. | **Гаилә.** | Өйдә кем яши? | 1 | 26.10.23 |
| | | Безнең гаилә. | 1 | 31.10.23 |
| | | Качышлы уйныйбыз | 1 | 1.11.23 |
| | | Тату гаилә. | 1 | 2.11.23 |
| | | Минем дуслар. | 1 | 7.11.23 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Әйдәгез, дуслашыйк | 1 | 8.11.23 |
| | | Минем туганнарым. | 1 | 9.11.23 |
| | | Безнең гаилә. | 1 | 14.11.23 |
| | | Әби күчтәнәче. | 1 | 15.11.23 |
| | | Дустыңны сыйла. | 1 | 16.11.23 |
| | | Сөт,чәй. | 1 | 21.11.23 |
| | | Кунакка барабыз. | 1 | 22.11.23 |
| 5 | **Кыш** | Кар ява. | 1 | 23.11.23 |
| | | Алсуны урамга киендерәбез. | 1 | 28.11.23 |
| | | А.Алиш "Куян кызы". | 1 | 29.11.23 |
| | | "Чанада шуабыз" рәсемен карау. | 1 | 30.11.23 |
| | | "Кышкы уеннар" . | 1 | 5.12.23 |
| | | "Куяннар" уенын өйрәнү. | 1 | 6.12.23 |
| 6. | **Яңа ел бәйрәме** | "Тиздән чыршы бәйрәме". | 1 | 7.12.23 |
| | | Б.Рәхмәтнең "Кыш бабай" шигырен ятлау. | 1 | 12.12.23 |
| | | Б.Рәхмәтнең "Кыш бабай" шигырен ятлау. | 1 | 13.12.23 |
| | | "Уйныйбыз да, җырлыйбыз да". | 1 | 14.12.23 |
| | | "Без бәйрәмгә әзерләнәбез". | 1 | 19.12.23 |
| | | "Бәйрәм концерты". | 1 | 20.12.23 |
| | | "Яңа ел бәйрәме". | 1 | 21.12.23 |
| 7. | **Минем йортым, минем авылым** | Минем авылым . | 1 | 26.12.23 |
| | | "Теләчем – туган ягым" | 1 | 27.12.23 |
| | | "Әлли-бәлли итәргә" бишек җыры. | 1 | 28.12.23 |
| | | Безнең урам. | 1 | 9.01.24 |
| | | "Алсуның яңа өе". | 1 | 10.01.24 |
| | | "Алсуда кунакта". | 1 | 11.01.24 |
| 8. | **Безнең авылда.** | "Безнең авылда". | 1 | 16.01.24 |
| | | Тема: "Зурлар һәм кечкенәләр". | 1 | 17.01.24 |
| | | "Кем нәрсә ярата?" татар халык әкияте. | 1 | 18.01.24 |
| | | "Песи һәм песи балалары" рәсемен карау. | 1 | 23.01.24 |
| | | Җ. Тәрҗемановның "Үзен бик чиста йөртә" шигырен уку. | 1 | 24.01.24 |
| | | "Кем Мияу дип әйтте?" | 1 | 25.01.24 |
| | | "Йорт кошлары". | 1 | 30.01.24 |
| | | Р.Батулланың "Елак әтәч" әсәрен уку. | 1 | 31.01.24 |
| | | "Без уйныйбыз". Уенчыклар, рәсемнәр | 1 | 1.02.24 |
| 10. | **Ватанны саклаучылар көне** | "Зур гаилә". "Безнең гаилә" рәсеме. | 1 | 6.02.24 |
| | | "Безнең әтиләр һәм абыйлар". | 1 | 7.02.24 |
| | | "Бабайга кунакка барабыз". | 1 | 8.02.24 |
| | | "Ватанны саклаучылар көне". | 1 | 13.02.24 |
| | | "Очучылар". | 1 | 14.02.24 |
| | | З.Туфайлованың "Шофёр булам" шигырен уку. | 1 | 15.02.24 |
| 11. | **8 нче март** | "Минем әнием ". | 1 | 20.02.24 |
| | | "Кояш гомере телим мин әнием сиңа!". | 1 | 21.02.24 |
| | | "Без әнигә булышабыз". | 1 | 22.02.24 |
| | | "Әбигә кунакка барабыз". | 1 | 27.02.24 |
| | | "Мин әнинең ярдәмчесе". | 1 | 28.02.24 |
| | | "Азат кунак чакыра". | 1 | 29.02.24 |
| 12. | **Кыргый хайваннар** | "Урманда". | 1 | 5.03.24 |
| | | "Аю белән куян". | 1 | 6.03.24 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | “Өч аю” | 1 | 7.03.24 |
| | **Әкияттә кунакта** | “Теремкәй” рус халык әкиятен сөйләү. | 1 | 12.03.24 |
| | | “Кыргый хайваннар”. | 1 | 13.03.24 |
| | | “Төлке, куян һәм Әтәч ” әкиятен сәхнәләштерү. | 1 | 14.03.24 |
| 13. | **Яз Җәй** | “Урамда яз”. | 1 | 19.03.24 |
| | | “Яз житте”. | 1 | 20.03.24 |
| | | “Яз җыры”. | 1 | 21.03.24 |
| | | “Кояш чык, чык...” | 1 | 26.03.24 |
| | | “Язгы күренешләр” | 1 | 27.03.24 |
| | | “Ак аю кунакка килгән”. | 1 | 28.03.24 |
| | | “Кошлар”. | 1 | 2.04.24 |
| | | Х.Вахитның “Уңган сыерчык” . | 1 | 3.04.24 |
| | | “Без уйныйбыз”. | 1 | 4.04.24 |
| | **Бәйрәмнәр** | “Бәйрәмгә барабыз”. | 1 | 9.04.24 |
| | | “Балалар бакчасында бәйрәм” дигән рәсем карау. | 1 | 11.04.24 |
| | | “Урманда зур концерт”- анимацион сюжет карау. | 1 | 16.04.24 |
| | **Җәй** | “Автобуста сәяхәт”. | 1 | 17.04.24 |
| | | Ж.Тәрҗемановның “Кикрикүк” шигырен уку. | 1 | 18.04.24 |
| | | “Мульфильмда кунакта”. | 1 | 23.04.24 |
| | | М.Мазуновның “Кәҗә” шигырен уку. | 1 | 24.04.24 |
| | | “Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау. | 1 | 25.04.24 |
| | | “Чәчәкләр – тормыш яме”. | 1 | 2.05.24 |
| | | “Матур җәй кил безгә”. | 1 | 3.05.24 |
| | | “Мин җәйне яратам”. | 1 | 7.05.24 |
| | | “Карга” эндәшен уку. | 1 | 8.05.24 |
| | | “Саф һавада”. | 1 | 14.05.24 |
| | | “Экология сукмагы буенча сәяхәт”. | 1 | 15.05.24 |
| | | “Тузганак чәчәген карау”. | 1 | 16.05.24 |
| | | “Әтәч үзенең гаиләсе белән ” хикәясе. | 1 | 21.05.24 |
| | | “Тилгән” эндәшен уку. | 1 | 22.05.24 |
| | | “Без уйныйбыз”. | 1 | 23.05.24 |

